КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 декабрь г.Казань № 1203

Юридик затларга Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Юридик затларга Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 25 декабрь, 1203 нче
карары белән расланды

Юридик затларга Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип юридик затларга Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2022 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы белән күздә тотылган Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калуга, популярлаштыруга һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру максатларында тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет акчасын алучы (алга таба – баш эш итүче) буларак Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр алучылар – түбәндәге критерийларга туры килә торган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш):

юридик зат Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән;

юридик зат үз эшчәнлеген Татарстан Республикасында китап басу һәм (яки) китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чаралар үткәрү өлкәсендә теркәлгән көннән кимендә биш ел гамәлгә ашыра;

юридик зат Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чаралар үткәрү өчен кадрлар ресурслары тиешле санга җиткерелгән.

4. Юридик затлар субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

юридик затларның Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре,

пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаска тиеш;

юридик затларның субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаска тиеш;

юридик затлар үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаска, аларга карата банкротлык процедурасы башланмаска, юридик затларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаска тиеш;

юридик затлар чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты булмаска тиеш;

юридик затлар бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

5. Субсидия түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны каплауга бирелә:

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруда катнашучы штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең эш хакын түләү һәм хезмәт өчен түләүгә түләүләрне исәпләүләр;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле җиһазлар, әсбаплар, җайланмалар, оештыру техникасы өчен аренда түләве;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен файдаланыла торган күчемсез мөлкәт (коммуналь һәм эксплуатация чыгымнарын кертеп) өчен аренда түләве;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле транспорт чараларын һәм ягулык-майлау материалларын сатып алу (арендалау) яки транспорт хезмәте күрсәтү;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле чыгым материалларын сатып алуга түләү;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен авторлык һәм чиктәш хокуклар, архив материалларыннан, компьютер графикасыннан файдаланган өчен түләүләр;

күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашырганда файдаланыла торган күргәзмә җиһазларын арендалау;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашырганда катнашучы штаттагы хезмәткәрләрнең командировка чыгымнары өчен түләү;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калуга, популярлаштыруга һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итүгә юнәлдерелгән тәкъдир итү һәм мәдәни-күңел ачу чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр өчен түләү;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калуга, популярлаштыруга һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итүгә юнәлдерелгән конкурслар, викториналар, акцияләр һәм башка кызыксындыру чаралары үткәрү;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен фото-, аудио-, видео- һәм басма материаллар җитештерү;

Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле типография хезмәтләре өчен түләү.

6. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4 + З_5 + З_6 + З_7 + З_8 + З_9 + З_{10} + З_{11} + З_{12},$$

монда:

С – юридик затка бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$, $З_4$, $З_5$, $З_6$, $З_7$, $З_8$, $З_9$, $З_{10}$, $З_{11}$, $З_{12}$ – бу Тәртиптә күрсәтелгән юнәлешләр буенча чагыштырма базар бәяләре ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар, аерым алганда:

$З_1$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруда катнашучы штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең эш хакын түләүгә һәм хезмәт өчен түләүгә түләүләрне исәпләүләргә чыгымнар;

$З_2$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле җиһазлар, әсбаплар, җайланмалар, оештыру техникасы өчен аренда түләвенә чыгымнар;

$З_3$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен файдаланыла торган күчемсез мөлкәт (коммуналь һәм эксплуатация чыгымнарын кертеп) өчен аренда түләвенә чыгымнар;

$З_4$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле транспорт чараларын һәм ягулык-майлау

материалларын сатып алуга (арендалауга) яки транспорт хезмәте күрсәтүгә чыгымнар;

$З_5$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле чыгым материалларын сатып алуга түләү;

$З_6$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен авторлык һәм чиктәш хокуклар, архив материалларыннан, компьютер графикасыннан файдаланган өчен түләүләр;

$З_7$ – күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашырганда файдаланыла торган күргәзмә җиһазларын арендалауга чыгымнар;

$З_8$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашырганда катнашучы штаттагы хезмәткәрләрнең командировка чыгымнары өчен түләүгә чыгымнар;

$З_9$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калуга, популярлаштыруга һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итүгә юнәлдерелгән тәкъдир итү һәм мәдәни-күңел ачу чараларын оештыру һәм үткәрү буенча хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнар;

$З_{10}$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калуга, популярлаштыруга һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итүгә юнәлдерелгән конкурслар, викториналар, акцияләр һәм башка кызыксындыру чаралары үткәрүгә чыгымнар;

$З_{11}$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен фото-, аудио-, видео- һәм басма материаллар җитештерүгә чыгымнар;

$З_{12}$ – Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыру өчен кирәкле типография хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар.

7. Субсидия алу өчен юридик затлар баш эш итүчегә түбәндәге документларны тапшыра:

баш эш итүче тарафыннан билгеләнгән форма буенча субсидия бирү турында гариза (алга таба – гариза);

гамәлгә кую документлары күчермәләрен, шулай ук субсидия алучы тарафыннан расланган аларга барлык үзгәрешләрне;

җитәкче билгеләү турындагы боерыкны яки гаризага имза куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документларны;

юридик затның җитәкчесе (башка вәкаләтле заты) һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган, юридик затның мөһере (булганда) белән расланган, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында ачылган субсидия күчереләчәк исәп-хисап счеты реквизитлары күрсәтелгән белешмә кәгазен;

юридик затның бу Тәртипнең 3 һәм 4 нче пунктларында каралган критерийларга һәм таләпләргә туры килүен раслый торган документларны;

юридик затның штат расписаниесен;

үткән финанс елы өчен бухгалтерлык балансын;

баш эш итүче тарафыннан билгеләнгән форма буенча субсидия күләме исәбен;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган документларның (шартнамәләр, йөкнамәләр, башкарылган эшләр актлары (күрсәтелгән хезмәтләр), исәп-фактуралар һ.б.) күчермәләрен.

8. Баш эш итүче юридик зат тарафыннан бирелгән гариза һәм документларны алар кергән көнне шнурланган, нумерланган һәм баш эш итүченең мөһере белән расланган журналда керү тәртибен саклап терки.

9. Баш эш итүче юридик зат тарафыннан бирелгән гаризаны һәм документларны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә аларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

б) юридик зат тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

в) бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

11. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, баш эш итүче әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә субсидия бирү турындагы гаризаны һәм бу Тәртипнең 7 нче пункты нигезендә тапшырылган документларны юридик затка кабул ителгән карарның нигезләве күрсәтелә торган хәбәрнамә белән кире кайтара.

12. Субсидия бирү турындагы карар, субсидия бирү турындагы килешү проекты белән бергә, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә юридик затка (алга таба – субсидия алучы) җибәрелә.

13. Субсидия бирү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелгән килешү нигез булып тора.

14. Килешүгә субсидия алучыдан ул имзаланган килешүне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә баш эш итүче тарафыннан имза куела.

15. Әгәр дә баш эш итүче тарафыннан килешү проекты җибәрелгән көннән календарь көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия алучы тарафыннан имзаланган килешү баш эш итүчегә тапшырылмаган булса, субсидия алучыга субсидия бирү турындагы карар гамәлдән чыгарылырга тиеш.

16. Килешүдә түбәндәге шартлар карала:

субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе;

субсидияләр хисабына капланырга тиешле чыгымнар исемлеге;

субсидия күләме һәм аны алу чыганагы;

субсидия күчерү вакытлары (дәвамлылыгы);

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидия алучының бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләренә Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы һәм баш идарәче тарафыннан мәҗбүри тикшерү үткәрү турындагы нигезләмәләр;

субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (җыелма) капиталларында мондый хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре катнашындагы коммерция оешмаларыннан тыш) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән баш эш итүче тарафыннан субсидия алучының бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру ризалыгы;

кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен субсидия алучының җаваплылыгы;

субсидия керү һәм аны сарыф итү буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бару турында таләп;

баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу факты ачыкланган очракта, субсидия алучы тарафыннан файдаланылган суммаларны кире кайтару тәртибе;

баш эш итүче тарафыннан билгеләнгән өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары.

17. Субсидия алу өчен бу Тәртип нигезендә бирелә торган документлардагы мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен җаваплылык субсидияләр алучыларга Россия Федерациясе законнары нигезендә йөкләнә.

18. Баш эш итүче субсидия алучының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына субсидияне баш эш итүче тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча күчерә.

19. Субсидия алучы баш эш итүчегә субсидия күчерү өчен билгеләнгән түләү реквизитлары үзгәрү турында алар үзгәргән көннән биш эш көне эчендә язма рәвештә хәбәр итә.

20. Субсидия алучылар субсидия керү һәм аны сарыф итүнең аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

21. Килешүдә каралган чыгымнар күләмнәре кимегән очракта, субсидия күләмен үзгәртү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү проекты субсидия алучыга чыгымнар күләмнәре кимү турында мәгълүмат бирелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә җибәрелә.

Субсидия бирү турында килешүгә өстәмә килешү баш эш итүче тарафыннан субсидия алучыдан аның тарафыннан имзаланган өстәмә килешү алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә имзалана.

22. Баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучының бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

23. Субсидия алучылар тарафыннан субсидия биргәндә бу Тәртип белән билгеләнгән, баш эш итүче һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган очракта, субсидия баш эш итүченең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

24. Бу Тәртипнең 23 нче пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылган очракларда, баш эш итүче субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге чараларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

25. Субсидияне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту баш бүлүче тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

26. Субсидияне файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү баш эш итүче тарафыннан килешүдә күрсәтелгән һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла. Бу Тәртипкә теркәлгән кушымтагы форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисаплылык субсидия алучы тарафыннан баш эш итүчегә хисап чоры тәмамланган вакыттан 30 көн эчендә кәгазьдә тапшырыла. Субсидия биргән айдан килә торган өченче ай хисап чоры булып тора.

27. Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча тормышка ашырылган чаралар субсидия бирү нәтиҗәсе була.

Субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе килешүдә баш эш итүче тарафыннан билгеләнә.

28. Бирелгән субсидияләр субсидия алучы тарафыннан баш эш итүченең түбәндәге очракларда тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

баш эш итүче һәм дәүләт финанс тикшерүе органнарының тикшерүләр фактлары буенча субсидия алучы тарафыннан бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән шартлар бозылулар ачыкланганда;

баш эш итүчегә дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә;

баш эш итүче соратып ала торган мәгълүмат һәм документлар тапшырылмаганда;

субсидия алучы Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгәндә;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгәндә.

Субсидия алучы тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару өчен билгеләнгән вакыт бозылганда, баш эш итүче бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакытлар тәмамланган көннән календарь көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне кире кайтару буенча чаралар күрә.

29. Төзелгән килешү баш эш итүче белән субсидия алучының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турындагы килешүне өзү турындагы өстәмә килешүгә имза кую юлы белән өзелә (кирәк булганда).

Юридик затларга Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

Форма

20__ елның ________________ хәленә карата
субсидияләр бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында
хисап

Субсидия алучының исеме: __________________________________
Дәвамлылыгы: ____________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасында китап басу традицияләрен саклап калу, популярлаштыру һәм аның буыннан-буынга күчүен дәвам итү буенча тормышка ашырылган чаралар саны | данә | 796 | | | | |

Субсидия алучының җитәкчесе ___________ __________________ _________________
(вәкаләтле зат) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис.) (имзаны таркатып язу)

Баш бухгалтер _______________ _______________ ______________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

20__ ел, «____» _____________

___________________________